ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.12.2020 Казан № 347-153/кс-2020

«Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте өчен техник суга (химик чистартылган) һәм агынты суларны (механик) чистартуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 07.12.2018 № 10-130/кс карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2021 елга төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2021 елга техник суга (химик чистартылган), агынты суларны (механик) чистартуга сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай табышына төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте өчен техник суга (химик чистартылган) һәм агынты суларны (механик) чистартуга 2019-2021 елларга тарифлар билгеләү турында» 07.12.2018 №10-130/кс карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 02.12.2019 № 10-147/кс карары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
07.12.2018 № 10-130/кс карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
04.12.2020 № 347-153/кс-2020 карары
редакциясендә) 1 нче кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте өчен техник суга (химик чистартылган) һәм агынты суларны (механик) чистартуга 2019-2021 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Техник суга тариф (химик чистартылган), (бер ставкалы), сум/куб. м | | | | | | Агынты суларны (механик) чистартуга тариф (бер ставкалы), сум/куб. м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 ел | | 2020 ел | | 2021 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | | 2021 ел | |
| | | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | | | | | | | | | |
| 1 | «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 44,15 | 46,74 | 46,74 | 47,66 | 47,66 | 50,52 | 4,77 | 5,00 | 4,88 | 4,88 | 4,55 | 4,55 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
07.12.2018 № 10-130/кс карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
04.12.2020 № 347-153/кс-2020 карары
редакциясендә) 2 нче кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте өчен техник суга (химик чистартылган) һәм агынты суларны (механик) чистартуга 2019-2021 елларга тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары

| Т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Техник су (химик чистартылган) | 2019 | 49065,23 | Х | - | - | 0,6 |
| | | 2020 | Х | 1 | - | - | 0,6 |
| | | 2021 | Х | 1 | - | - | 0,6 |
| 1.2 | Агынты суларны (механик) чистарту | 2019 | 677,34 | Х | - | - | 0,41 |
| | | 2020 | Х | 1 | - | - | 0,41 |
| | | 2021 | Х | 1 | - | - | 0,41 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге